| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2020 Казан шәһәре № 5-2/кс-2020

«Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчә торган суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен, әлеге карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 14.02.2020
№ 5-2/кс-2020 карарына кушымта

# Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу белән шөгыльләнүче «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Тәртип саны | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр |
| | Питрәч муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Питрәч коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе* | | | | |
| 1.1 | Кощаково авыл җирлеге кулланучылары | 21,87 | 22,74 | 25,65 | 26,59 |
| 1.2 | Пановка авыл җирлеге кулланучылары | 22,47 | 23,20 | 22,40 | 23,30 |
| 1.3 | Белкино, Екатериновка, Кибәч, Кибәк Иле, Кавал, Күн, Колай, Керәшен Сәрдәсе, Ленино-Кокушкино, Надеждино, Татар Казысы, Питрәч, Пимәр, Татар Тау Иле, Чыты, Шәле, Янсуар авыл җирлекләрендәге кулланучылар | 22,35 | 23,25 | | |
| 1.4 | Колай, Ленино-Кокушкино, Питрәч авыл җирлегендәге кулланучылар | | | 27,62 | 28,71 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге